| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШУБАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
2022 г.

КАРАР
№11

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында**

«Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында " 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслауга карата,Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында " 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы карарына нигезләнеп, Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы, 2022 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Вакытлыча Шубан авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы: С.З.Васильева .

Татарстан Республикасы
Балтач районы Шубан авыл җирлеге
башкарма комитетының
2022 елның 19 июле, 11-номерлы карарына
КУШЫМТА

### Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге бюджет керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм вакытлары

Әлеге Тәртип Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә эшләнде, «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында " 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), Территориаль мәҗбүри медицина иминияте, бюджет керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә (Алга таба - исемлек, баш администратор) үзгәрешләр кертү механизмын һәм вакытларын билгели.

Баш администраторларның составы яки функцияләре үзгәргән очракта,шулай ук Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге бюджетының керем кодлары классификациясе һәм бирү принциплары үзгәргәндә, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәрен классификацияләү кодларының баш администраторларына беркетелгән составы үзгәргәндә, Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет Палатасы боерыгы нигезендә, Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 нче елның 6 декабрендәге 15 –номерлы " Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге бюджет керемнәренең Баш администраторлары исемлеген раслау турында" карарына үзгәрешләр кертмичә кертелә.

Исемлеккә үзгәрешләр федераль һәм төбәк законнарына бюджет керемнәрен классификацияләү кодларының баш администраторларына беркетелгән составына үзгәрешләр кертү өлешендә кертелә.